**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛАН-БӘКСӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422723, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Алан-Бәксәр авылы, Үзәк ур., 19

**СОВЕТ АЛАН-БЕКСЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422723, Республика Татарстан, Высокогорский район, с. Алан-Бексе, ул. Центральная, 19

тел./факс 8(84365) 63-9-51, e-mail: AlanB.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**5 май 2018 ел** **№ 126**

**Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советының 2017 елның 12 апрелендәге 71 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге территориясендә гавами тыңлаулар оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында»**

Алан-Бәксәр авыл җирлегенең норматив хокукый актларын «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 29 декабрендәге 455-ФЗ номерлы Федераль законына яраклаштыру максатларында, Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советының 2017 елның 12 апрелендәге 71 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге территориясендә гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә (алга таба текст буенча - Нигезләмә):

1.1. Нигезләмәнең 6.2 пунктының 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) генераль планнар, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектлары, территорияне планлаштыру проектлары, территорияне ызанлау проектлары, территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләре проектлары; өстә санап үтелгән, расланган документларның берәрсенә үзгәрешләр кертү проектлары, капиталь төзелеш объектыннан файдалануга рөхсәт бирү турындагы карарларның проектлары, рөхсәт ителгән төзелешнең чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирә торган карарлар проекты, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүгә рөхсәт бирү турындагы карарларның проектлары, җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалануның бер төрен башка төргә үзгәртү мәсьәләләре буенча, Җирдән файдалану һәм төзелеш алып баруның расланган кагыйдәләре булмаган очракта, җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар үткәрелә, аларны оештыру һәм үткәрү тәртибе авыл җирлеге Уставы һәм (яисә) җирлек Советының Шәһәр төзелеше

эшчәнлегенә кагылышлы законнарга нигезләнеп эшләнгән норматив хокукый акты белән билгеләнә.

1.2. Нигезләмәнең 6.2 пунктына түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча өстәргә:

«5) муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеш стратегиясе проекты.».

1.3. Нигезләмәнең 6.2 пунктын түбәндәге эчтәлекле 6 пунктча белән тулыландырырга:

«6) 6.2 пунктында күрсәтелгән проектлар һәм мәсьәләләр буенча гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе авыл җирлеге уставы һәм (яисә) җирлек Советының норматив хокукый актлары белән билгеләнә һәм муниципаль берәмлек халкына гавами тыңлаулар уздыру вакыты һәм урыны турында алдан хәбәр итүне, муниципаль хокукый акт проекты белән алдан таныштыруны, муниципаль берәмлек халкының гавами тыңлауларында катнашуны, гавами тыңлауларның нәтиҗәләрен, кабул ителгән карарларның дәлилләнгән нигезләмәләрен дә кертеп бастырып чыгаруны (халыкка җиткерүне) тәэмин итүне күздә тотарга тиеш.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча  һәм “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында” Интернет мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Совет рәисе,
Алан-Бәксәр авыл җирлеге башлыгы З.Р.Гарифуллина